ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау тиемер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**15 май 2019 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 164**

**Красносельский авыл җирлеге Советынын 2019 елның 22 нче ноябрендәге 148 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законы нигезендә, «Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып», Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Красносельский авыл җирлеге Советының 2019 елның 22 нче ноябрендәге, 148 нче номерлы «Җир салымы турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 пунктны түбәндәге эчтәлекле 3.1.1 пункты белән тулыландырырга:

«3.1.1. Салым түләү салым түләүчеләр тарафыннан җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча башкарыла.

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал тәмамланганнан соң, узган чордан соң килгән икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла»;

2) 5 пунктта «салым түләүче-оешмалар һәм» сүзләрен төшереп калдырырга»;

3) 5.1., 5.2 пунктларны «төшереп калдырырга»;

4) 7.1 пунктының 4 абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташламаны бирү өчен нигез булып Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы яисә сугышта катнашучы таныклыгы, күрсәтелгән ташламаны алу хокукын раслаучы башка тиешле документлар тора»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. 3.1.1 пунктының икенче абзацы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары Никитенко Р. Р. йөкләргә.

Совет рәисе
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин